# Чишмә башы

2 нче сан, декабрь

**Хәсәншәех балалар бакчасы**

**Хөрмәтле әти-әниләр!**

**Яңа ел белән котлыйбыз сезне! Алдагы өр-яңа ел бары бәхет-куанычлар гына алып килсен. Туасы таңнар тыныч булсын. Гомер юлларыгыз шатлык белән тулып торсын һәрчак. Кызыклы очрашулар, бәхетле мизгелләр күп булсын! Эшләрегездә уңышлар юлдаш булсын, күңелләрегездәге мәрхәмәтлелек бар җиһанны яктыртсын. Йортларыгызга авырулар, хәвеф-хәтәрләр, бәла-казалар килмәсен. Гаиләләрегездә бәхет уты һәрвакыт сүнмичә янып торсын! Яңа ел белән сезне, киләсе еллар бәхет китерүче еллардан булсын!**

**Хәсәншәех балалар бакчасы коллективы**

# Бездә күңелле

Декабрь  ае конкурсларга бай булды.

Фасхутдинов Ринат дистанцион рәвештә уздырылган “ Кышкы уен төрләре” викторинасында 1 дәрәҗәдәге дипломга лаек булды.

Фахрутдинов Мурат  Чистай шәһәре үткәргән  “Шәвәли шуклыгы” конкурсында Ш.Галиев шигырен сөйләп призер дипломына лаек булды, Закиров  Артур һәм Сагитзянова Сәйдә  катнашучы диплом алдылар.

Бакчабызда “ Яңа ел бизәкләре” бәйгесендә һәр гаилә кул эшләре ( алып килеп дипломнар белән бүләкләнделәр.

Район буенча үткәрелгән “Чыршы уенчыгы”  бәйгесендә Хлопушин Данир ,Фахрутдинова Язгөл һәм Гафурова Нәфисә җиңүчеләр булдылар.

Балаларны уңышлары белән котлыйбыз. Киләчәктә дә алар белән горурланырга насыйп булсын.







**Исәнме, чыршы, исәнме!**
**Тагын да бер ел үтте.**
**Күңелле чыршы бәйрәмен**
**Балалар күптән көтте.**












# Әти-әниләр иҗаты

*Безнең балалар бакчасына йөрүче балаларның әти-әниләре арасында шигырьләр иҗат итүчеләр дә бар. Сезгә Фахрутдинова Гөлзиләнең бер шигырен тәкъдим итәбез. Гөлзиләгә киләчәктә тагын да зур иҗат уңышлары телибез.*

**Әкрен генә атлап киләм**
**Карга чумган сукмаклардан.**
**Бала чагым көлә сыман**
**Еллар аша ераклардан.**
**Бала чагым килә сыман,**
**Кулларына тотып чана.**
**Килеп чумам шул көртләргә**
**Качам диеп чаба-чаба.**
**Чырык-чырык көлә торган**
**Алсу йөзле кызны күрәм.**
**Көтче мине сабый чагым,**
**Уйларымда сиңа киләм.**
**Кар йомарлап атар булып**
**Кулларыма аны алам.**
**Китмә миннән карлы кышым,**
**Мин мәңгегә синдә калам.**
**Китмә миннән сабый чагым,**
**Ак күңелле керсез чагым.**
**Итек киеп,чана тотып,**
**Тау шуарга чыгам тагын.**
**Бозга каткан бияләйләр,**
**Салкын куллар төшә искә.**
**Ак карлардай керсез чагым**
**Чыкмый минем һич тә истән.**
**Җиргә кышлар килгән саен**
**Бала чакка кайтам сыман.**
**Хыялымны күмеп үтә**
**Еллар дигән аксыл томан...**

**Кышкы чорда куркынычсызлык чаралары.**

Кыш - тылсымлы вакыт. Кыш - хуш исле чыршылар, күңелле бәйрәмнәр вакыты. Ләкин кыш үз куркынычларын да китерә.

1.Баланы урамга ничек дөрес киендерергә: баланы урамга җибәргәнче аның ничек киенгәнен карагыз: җылы, берничә кат кием. Мөмкин кадәр йонлы киемнәр сайлагыз. Йон нык һәм сыгылмалы материал. Кышкы кием баланың зурлыгына туры килергә тиеш һәм хәрәкәтләрне чикләргә тиеш түгел. Бу аеруча аяк киемнәре өчен актуаль. Артык кысан итекләр кан басымын тарайталар, нәтиҗәдә аяклар тизрәк суыналар. Аяк киемен сайлаганда бер размерга зуррак алыгыз. Итекләр су үткәрмәүчән булырга тиеш.

2. Чанада шуу: Балалар чанада шуарга яраталар, шуу чанада , ләкин алар иминлек кагыйдәләрен белергә тиеш. Чанада шуатырган урын ачык булырга тиеш. Баланың юлында агачлар һәм куаклыклар булмаска тиеш. Шулай ук тауның ахыры транспорт юлына чыгарга тиеш түгел.

3.Туңу билгеләре: Ешрак борын, колаклар, яңаклар һәм бармаклар туңа. бөтенесе азапланалар борын, колаклар, яңаклар һәм бармаклар. Туңу билгеләре: кымырҗу, телсезләнү, чәнчеп алу яки пешерү. Җәрәхәтләнгән өлешләр агара, кызара яки зәңгәр була.

4.Әгәр дә бала өшесә:
- иң беренче җылы урынга барырга кирәк- җәрәхәтләнгән өлешләрне чиста йомшак тукыма белән уыгыз, кар белән умагыз;
- салкын һәм юеш киемнәрне коры, йомшак, иркен киемгә алыштырыгыз;
- организмны акрынлап җылытыгыз: какао яки чәй эчерегез;
- ярдәмгә табибны чакырыгыз.

5. Шарф, бияләйләр һәм перчаткалар. Шарфны кием эченә кертеп калдырыгыз. Өстәмә бер кием перчаткалар яки бияләйләр булырга тиеш, чөнки перчатка югалырга, яки чыланырга мөмкин.
Саф һавада уеннар чыныгу һәм профилактика өчен бик мөһим. Ләкин урамга чыгар алдыннан яхшылап әзерләнегез.